# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге составына керүче Каенлык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

11 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Каенлык авылында зиратны төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2022 елның 11 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 144 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 75 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 75 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге составына керүче Каенлык авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныырга.

2. «Зур Фролово авыл җирлегенең Каенлык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Каенлык авылында зиратны төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип таныырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Каенлык авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Зур Фролово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ О.Г. Масленцева

Зур Фролово авыл җирлеге
башлыгы __________ О.Г. Масленцева